| | |
|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.07.2019 Алексеевск ш т б № 257

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне беренче укылышта кабул итәргә. (Кушымта №1).

Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, алар өстендә эшләүне дәвам итәргә.

2. Алексеевск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» гы карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның фикер алышуында катнашуы тәртибен расларга (Кушымта №2).
3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы бинасындагы мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарга кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карауны законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә (Хамадеев Ф. Я.).
5. Алексеевск муниципаль районы Советы депутатларының әлеге карарга төзәтмәләр рәвешендәге тәкъдимнәре комиссиягә 2019 елның 5 августына кадәр кертелә дип билгеләргә.
6. Гражданнарның әлеге карарга тәкъдимнәре авторның фамилиясен,

исемен, атасының исемен, туган елын, адресын күрсәтеп, язма рәвештә, Алексеевск штб, Совет мәйданы, 1йорт адресы буенча урнашкан комиссиягә җибәрелә дип билгеләргә.

7. Алексеевск муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча ачык тыңлауларны муниципаль район Советының утырышлар залында 2019 елның 9 августына сәгать10-00 га билгеләргә.

Гавами тыңлаулар Алексеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 194 номерлы карары белән расланган Алексеевск муниципаль районында ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезендә үткәрелә.

8. Комиссиягә район Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм гражданнарның әлеге карарга тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, аларны эшләп бетерергә һәм 2019 елның 14 августында район Советы каравына кертергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

10. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль законның 44 матдәсендәге 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

**Муниципаль район башлыгы**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы Советының
2019 елның 25.07
257номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

**1. 6 матдәдә**

**а)** 1 пунктта:

- 16 пунктчаны түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга «җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты урнаштыру мөмкинлеге һәм параметрлары буенча планлаштырылган шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән хәбәрнамәгә туры килү турында хәбәр итү, шәхси торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру рөхсәт ителмәве турында язылган хәбәрнамәләр, тиешле җирлекара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзегәндә яки реконструкцияләгәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килү-килмәү турында хәбәрнамәләр җибәрү, Россия Федерациясе гражданнары законнары нигезендә авылара территориядә урнашкан үзирекле корылмаларны сүтү турында карар, авылара территориядә урнашкан үзирекле төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар кабул итү, максатчан билгеләнеше буенча яки Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир һәм авыллар арасында урнашкан җир кишәрлеген тартып алу, авылара территориядә урнашкан үзирекле корылмаларны сүтү яки аны Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү;»;

- 36 пунктчада «хокук» сүзеннән соң «аз санлы җирле халык һәм башкалар» сүзләрен өстәргә;

- 37 пунктчадагы «муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементлары исемнәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

**2. 8 матдәдә**

**а)** 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

14) «Кулланучылар хокукларын яклау турында»1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру;

**3. 22 матдәдә**

**а)** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар халык, район Советы, район башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә. Халык инициативасы белән яки район Советы инициативасы буенча үткәрелә торган тыңлаулар

район Советы тарафыннан, ә район башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә торган тыңлаулар район Башлыгы тарафыннан билгеләнә. »;

**б)** 10 пунктта «әлеге матдәнең 3 пунктында күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

**4. 32 матдәдә**

**а)** 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район Советы депутаты вәкаләтләре Алексеевск муниципаль районы составына керүче җирлек башлыгы вазифасына кергән көннән яки авыл җирлеге составына әлеге җирлек кергән район Советы депутаты итеп сайланган көннән башлана һәм яңа сайланган җирлек башлыгы вазифасына кергән көннән яки әлеге җирлектән район Советына депутат сайлау турындагы карар үз көченә кергән көннән башлап туктатыла.»;

**б)** 7 пунктта 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә, оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюзда катнашудан тыш, съездда (конференцияләрдә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш); муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлеше) белән идарә итүне гамәлгә куючы яисә гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очраклар»;

**5. 51 матдәдә**

**а)** 1 пунктның 2 пунктчасындагы 12 абзац үз көчен югалткан дип санарга;

**б)** 1 пунктның 5 пунктчасындагы 14 абзац үз көчен югалткан дип санарга;

**в)** 1 пунктның 7 пунктчасындагы 13 абзацында «хокук» сүзеннән соң «аз санлы җирле халык һәм башкалар» сүзләрен өстәргә;

**г)** 9 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Куллланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.;

**6. 79 матдәдә**

**а)** 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Халыкка таратылырга тиешле мәгълүмат булган муниципаль актлар халыкка хәбәр ителергә тиеш. Муниципаль актны игълан итү акт текстын районның рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре

порталында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла яки хокукый акт текстын, үзәкләштерелгән тәртиптә, район халкына җибәрү (тарату), шул исәптән махсус басмалар рәвешендә яки хокукый акт текстын район торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән стендларның саны һәм аларның урнашу урыннары район Советы тарафыннан раслана һәм район халкы тарафыннан муниципаль хокукый акт тексты белән тоткарлыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару булып, аның тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган Вакытлы матбугатта беренче бастырып чыгару санала. Хокукый акт текстын башка массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге басманың рәсми булып торуы турында билге булырга тиеш.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәрле басмадан файдаланырга хокуклы. Рәсми челтәр басмасында муниципаль хокукый актның тулы тексты басылып чыккан (урнаштырылган) очракта басмада зур күләмле график һәм таблица кушымталары күрсәтелмәскә мөмкин.

Шулай ук рәсми бастырып чыгару булып хокукый акт яки хокукый акт проекты текстын «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында», «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәм районның массакүләм мәгълүмат чаралары челтәрле басмасында урнаштыру тора.

Татарстан Республикасының «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын һәм аңа үзгәрешләр кертү турында муниципаль актларны рәсми бастырып чыгару чыганагы буларак шулай ук хокукый акт текстын Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» бүлегендә «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру кулланыла.

Норматив-хокукый актлар Татарстан Республикасының 2 дәүләт телендә бастырып чыгарылырга тиеш.

Федераль закон белән тарату чикләнгән мәгълүмат булган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) рөхсәт ителми.

**б)** 9 пункт үз көчен югалткан дип санарга;

**7. 86 матдәдә**

а) 7 пункттагы 5 пунктча үз көчен югалткан дип санарга:

**Муниципаль район башлыгы**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**

Алексеевск муниципаль
районы Советының
2019 елның 25.07
257 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАР ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ АНЫҢ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУЫ ТӘРТИБЕ**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советы аппаратына язма рәвештә түбәндәге адрес буенча кертелә: 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск ш. т. б., Совет мәйданы, 1 йорт.

Тәкъдимнәр «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты тексты Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылганнан соңгы эш көннәрендә 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар (конвертта «Устав буенча фикер алышу» тамгасы белән) шәхсән яки почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Алексеевск ш. т. б., Совет мәйданы, 1 йорт.

**Муниципаль район башлыгы**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**